**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан,423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

23.01.2020 ел **Чирмешән авылы** № 12

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында нәселле терлек үрчетүгә чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2019 елның «13» декабрендәге 256 номерлы «2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты турында» карары белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында нәселле терлек үрчетүгә чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү турында Нигезләмәне расларга (1нче номерлы кушымта).
2. Әлеге карарны рәсми хокукый порталда (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесенең
2020 елның 23 гыйнварындагы
12 нче номерлы Карарына
1 нче кушымта

**2020 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында нәселле терлек үрчетүгә чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү турында**
**Нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2019 елның «13» декабрендәге 256 номерлы «2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты турында» карары нигезендә эшләнде һәм 2020 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында нәселле терлек үрчетүгә чыгымнар өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибен билгели (алга таба - субсидия).

1.1. Субсидияләр нәселле үгез-җитештерүчеләр орлыгын һәм орлык саклау өчен сыек азот сатып алуга бирелә һәм районның шәхси ярдәмче хуҗалыкларында нәселле терлек үрчетү өчен башкарыла торган чыгымнарның бер өлешен каплый.

2. Субсидияләр бирү агымдагы финанс елында каралган бюджет ассигнованиеләре лимиты чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Субсидияләр бирүнең максатлары - шәхси ярдәмче хуҗалыкларда мөгезле эре терлекләрнең үрчем өчен (случный) контингентын ясалма орлыкландыру, сыерларның продуктивлыгын арттыру һәм мөгезле эре терлекләрнең төрле авырулары таралуын булдырмау.

4. Субсидияләр Чирмешән муниципаль районында теркәлгән, Чирмешән муниципаль районы территориясендә терлекчелек өлкәсендә хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче, нәселле үгез-җитештерүчеләр орлыгын һәм орлык саклау өчен сыек азот сатып алу чыгымнарын башкаручы авыл хуҗалыгы оешмаларына, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына бирелә.

4.1. Субсидия Россия Федерациясе законнары нигезендә үзгәртеп кору, бетерү процедуралары яки бөлгенлек (банкротлык) процедурасы булмаганда бирелә.

Субсидия Татарстан Республикасы һәм (яисә) Чирмешән муниципаль районы бюджеты чараларын максатчан файдаланмаганда, шул исәптән аларны биргәндә билгеләнгән шартларны бозып, һәм аларны Татарстан Республикасы һәм (яисә) Чирмешән муниципаль районы бюджеты керемenә кайтармаган очракта бирелә алмый.

5. Субсидия алу өчен Алучы җирлекнең Башкарма комитетына субсидия бирүгә заявка бирә әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән документларны кушып.

Башкарма комитет гаризаларны теркәү журналына гаризаны кергән көнендә

терки һәм әлеге тәртипнең 7 пункты нигезендә карар кабул итә.

Субсидияләр үрчем өчен (случный) контингентка һәр баш мөгезле эре терлеккә орлыкларның ихтыяҗын исәпкә алып бер тапкыр бирелә, әмма бер баш мөгезле эре терлеккә 750 сумнан артык түгел.

6. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы оешмалары, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары район Башкарма комитетына (алга таба - Башкарма комитет) түбәндәге документларны тапшыралар:

- Башкарма комитет җитәкчесе исеменә язма мөрәҗәгать форма буенча (1нче кушымта), керүче документлар журналында теркәлә торган чыгым суммасын күрсәтеп;

- юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә шәхси эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә әлеге субсидияне алучының урнашкан урыны буенча, заявка бирү датасына кадәр 30 көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән.

- сперма китерү шартнамәсенең күчермәсен;

- түләү өчен счет күчермәсен;

- тиешле субсидия турында белешмә-исәп расланган форма буенча (2 нче кушымта).

7. Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Башкарма комитет күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә Алучының документларын, кабул ителгән карарның нигезләре күрсәтелгән хәбәрнамә кушымтасы белән, кире кайтара.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

субсидия Алучының әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү таләпләренә һәм шартларына туры килмәве;

шушы Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

субсидия Алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы;

бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

8. Өч эш көне дәвамында район Башкарма комитеты, җирлекнең Башкарма комитеты һәм субсидия алучы Татарстан Республикасы Финанс-бюджет палатасында билгеләнгән типик форма буенча субсидия бирү турындагы Килешүгә имза куялар.

Субсидияләр Татарстан Республикасы Финанс-бюджет палатасында билгеләнгән типик форма нигезендә төзелгән субсидия бирү турындагы килешү нигезендә бирелә.

Субсидия Алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$V = S \times Z$,

кайда

V – Субсидияләр күләме

S – Мөгезле эре терлекләр башы саны

Z – башкарылган чыгымнар күләме.

Субсидияләр бирү турындагы килешүдә түбәндәгеләр каралган:

- субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

- финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булып торган чыгымнар юнәлешләре;

- субсидия күчерү тәртибе;

финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидияләр булган чыгымнар турында хисап бирү тәртибе, сроклары һәм рәвешләре, субсидия Алучының чыгымнарын бюджеттан тыш (хосусый) финанслау буенча;

- хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлешләрен агымдагы финанс елында кире кайтару тәртибе;

- район Башкарма комитеты, Финанс-бюджет палатасы, Контроль-хисап палатасы тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүгә субсидия Алучының ризалыгы

9. Субсидияләр алучылар мөгезле эре терлекләр өчен сперма сатып алу фактын раслаучы документларны тапшырырга тиеш: нәселле үгез-җитештерүчеләр орлыкларын һәм орлыкны саклау өчен сыек азот сатып алган өчен счет-фактура, товар-транспорт накладнаясы, түләү йөкләмәләре күчермәләре 2020 елның 15 июленә кадәр.

10. Баш идарәче (распорядитель) субсидия алучыларның, субсидияләрне җирле бюджеттан биргәндә билгеләнгән шартлар һәм максатлар нигезендә, аларны файдалануга билгеләнгән тәртиптә финанс контролен гамәлгә ашыра.

11. Субсидияне нигезсез алу фактларын ачыклаган, шулай ук субсидия алучы тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр бирелгән очракта, идарәче (распорядитель) субсидия алучының җирле бюджетка алынган субсидияне тулысынча кире кайтаруы турында карар кабул итә һәм 10 эш көне эчендә субсидия алучыга кабул ителгән карар һәм алынган субсидияне кире кайтару турында язмача хәбәр итә.

12. Субсидия алучы күрсәтелгән хәбәрнамәне алганнан соң 30 эш көне эчендә нигезсез алынган субсидияне җирле бюджетка күчерергә тиеш.

13. Субсидия алучы нигезсез алынган субсидияне җирле бюджетка тулы күләмдә күчермәгән очракта, әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында билгеләнгән срокта, күрсәтелгән чаралар баш идарәче (распорядитель) тарафыннан суд тәртибендә түләттерелә.

14. Район Башкарма комитеты һәм Финанс-бюджет палатасы, район Контроль-хисап палатасы субсидия алучыларга акча бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә тикшерү уздыралар.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты
раслаган Нигезләмәгә
1 нче кушымта
23.01.2020 ел №12

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесенә
________________________________
(кемнән) ______________________________
_________________________________

**ГАРИЗА**

Нәселле үгезләр - җитештерүчеләрнең орлыгын һәм орлык саклау өчен сыек азот сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга тиешле субсидияне, җирле бюджет чаралары исәбеннән, киләсе күләмдә бирүегезне сорыйм:
_________________ (__________________________) сум _________ тиен

Кушымта:
- ЕГРЮЛдан өземтә;
- сперма китерү шартнамәсенең күчермәсе;
- түләү өчен счет күчермәсе;
- тиешле субсидия турында белешмә-исәп;

Исәп-фактура, ТТН, нәселле үгез-җитештерүчеләрнең орлыгын һәм 2020 елның 15 июленә кадәр орлыкны саклау өчен сыек азотны сатып алуга түләү йөкләмәсенең күчермәләрен тапшырырга вәгъдә итәм.

________________/______________
_
Дата __________________________

2нче кушымта

Раслыйм:
ТР Чирмешән муниципаль районында
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
________________________ ________________

2020 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында
шәхси ярдәмче хуҗалыкларда нәселле
көтүлекләр үрчетү чыгымнарның
бер өлешен каплауга субсидияләр бирү өчен
исәп-хисап белешмәсе
__________________________ ИНН ____________________

| **Мөгезле эре терлек саны** | **Чыгымнар суммасы** | **Субсидия суммасы, сум.** |
|---|---|---|
| | | |

Хуҗалык җитәкчесе ______________________ /___________________

Хуҗалыкның баш хисапчысы ______________________ /____________________